**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлегенең Льяшево торак пунктында халык җыены карары**

**7 декабрь, 2021 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлегенең торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлегенең Льяшево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 1000 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә.

2. Гражданнардан алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (авыл эчендәге юлларны ремонтлау, вак таш, ком сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, эш, килешү буенча түләү).;

- Льяшево т. п. да су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

- Льяшево т.п. урамнарны яктырту челтәрләрен карап тоту (Лампалар, Яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга. https://tetushi.tatarstan.ru/

**Җитәкче** **И.А. Тихонова**